**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Важашур авыл җирлеге башлыгы**
**карары**

**2023 елның 9 ноябре** **№ 4**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 20 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок Сутер авылы, Яшьләр урамы, 1д йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 20 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок Сутер авылы, Яшьләр урамы, 1д йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәклә рдән; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Починок Сутер авылында Ленин, Бакча, Яшьләр, Яңа урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау: проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Починок Сутер авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Починок Сутер авылында урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу;

- Сутер Починок авылында янгын гидрантларын, янгын краннарын сатып алу һәм урнаштыру, янгынга каршы инвентарь сатып алу, проект-смета документлары;
- Починок Сутер авылында су башнясын һәм суүткәргеч челтәрне карап тоту, проект-смета документлары;
- Починок Сутер авылы Ленин урамындагы елга аша чыгу юлын ремонтлау;
- Починок Сутер авылындагы чишмәне ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Важашур авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов